Чыганак: Габдрахман Әпсәләмов: әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / ТР Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; җав. мөх-ре И. Г. Һадиев. – Казан : Милли китап, 2009. – 32 б.

Габдрахман Әпсәләмовның гомеръязмасы:

1911 ел, 28 декабрь – Пенза губернасының Краснослободск өязе (хәзерге Мордовия Республикасының Рыбкино районы) Иске Аллагол авылында туа.

1919-921 еллар – башлангыч мәктәптә белем ала.

1922-1928 еллар – Мәскәүдә Н.Нариманов исемендәге 27 номерлы татар мәктәбендә белем ала.

1928 ел – ФЗӨ мәктәбенә укырга керә.

1931-1937 еллар – Мәскәү заводларында слесарь һәм токарь булып эшли, техникумда белем ала.

1937 ел – «Совет әдәбияты» журналында «Маһинур» исемле беренче хикәясе басыла.

1938-1940 еллар – М.Горький исемендәге әдәбият институтының татар бүлегендә белем ала.

1940 ел – Татарстан дәүләт нәшриятында яшь әдипнең балалар өчен язылган «Киләчәк безнеке» исемле пьесасы басыла.

1941 ел – «Бәхет кояшы» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. А.Гайдарның «Тимур һәм аның командасы» повестен тәрҗемә итә.

1941 ел, август – язучы фронтка китә.

1941-1943 еллар – Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры.

1943-1945 ел май – «Ватан өчен сугышка» газетасының җаваплы секретаре.

1944 ел – Татарстан дәүләт нәшриятында «Төньяк балкышы» дип аталган хикәяләр җыентыгы басыла.

1945 ел, июнь – 1946 ел, апрель – «Сталин сугышчысы» газетасы редакциясендә эшли.

1946 ел – СССР Язучылар союзы члены. «Ак төннәр» повесте басылып чыга.

1947 ел – «Зәңгәр кыя» хикәяләр җыентыгы дөнья күрә.

1950 ел – А.Фадеевның «Яшь гвардия» романын тәрҗемә итә.

1951 ел – Э.Г.Казакевичның «Ордерда яз» романын тәрҗемә итә.

1951 ел, сентябрь – «Совет әдәбияты» журналында «Газинур» романы басылып чыга.

1958 ел – «Сүнмәс утлар» романы басылып чыга.

1959 ел – «Сүнмәс утлар» романы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

1960 ел – «Мәңгелек кеше» романы басылып чыга.

1964 ел – «Мәңгелек кеше» романы рус теленә тәрҗемә ителә.

1965 ел – «Ак чәчәкләр» романы басылып чыга.

1968 ел – «Ак чәчәкләр» романы рус теленә тәрҗемә ителә. «Миңа унтугыз яшь иде» повесте, «Яшел яр» романы басылып чыга.

1972 ел – «Күк күкрәр» романы басылып чыга.

1975 ел – «Яшел яр» романы рус теленә тәрҗемә ителә.

1977 ел – Муса Җәлилгә багышлап «Агыла болыт» романын яза.

1979 ел, 7 февраль – озакка сузылган авырудан соң Габдрахман Әпсәләмов Казанда вафат була.